РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» февраль 2026 ел г. Альметьевск № 286

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының «2025 елга
Әлмәт муниципаль районында хокук
бозуларны профилактикалау муниципаль
программасын раслау турында»
2025 елның 22 августындагы 2077 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау муниципаль программасын раслау турында»2025 елның 22 августындагы 2077 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

- программа паспортының «программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны җирле бюджет хисабына финанслауның гомуми күләме 5505,502 мең сум тәшкил итә.<br>Искәрмә:* программаны муниципаль бюджет акчалары исәбеннән финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм реаль мөмкинлекләрдән чыгып төгәлләштерелергә тиеш. |

- «Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү» 3 бүлегенең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Программаны җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслауның гомуми күләме 5505,502 мең сум тәшкил итә»;

2025 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау муниципаль программасына кушымтада:

- «3 нче мәсьәлә: иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән гражданнарны, шул исәптән балигъ булмаганнарны һәм яшьләрне, ирегеннән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итү» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.3, 3.4, 3.5 пунктлар өстәргә:

заказ № 4553-940

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга; ирекtән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән затларга эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтү. | җинаять-башкарма инспекциясе Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 2025 ел | | | | |
| 3.4. Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга, ирекtән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзага хөкем ителгән затларга документларны торгызуда һәм рәсмиләштерүдә ярдәм күрсәтү. | җинаять-башкарма инспекциясе Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 2025 ел | | | | |
| 3.5. Ирекtән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгәннәр артыннан контроль, профилактик эшне көчәйтү һәм рейдлар үткәрү . | уголовно-җинаять-башкарма инспекциясе Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | 2025 ел | | | | |

- «4 нче бурыч: җәмәгать иминлеген тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлеген оештыру һәм җәмәгать урыннарында хокук тәртибен һәм иминлекне тәэмин итү һәм җинаятьләрне ачу өчен заманча техник чаралар кертү» бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.7, 4.8 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.7. Хокук тәртибен саклау буенча җәмәгать пунктын матди-техник | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль | 2025 ел | | | | 1 000,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| тәэмин итү һәм аның эшчәнлеге | районы башкарма комитеты | | | | | |
| 4.8. Җәмәгать сак пунктларында саклау сигнализациясен урнаштыру | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Яшьләр эшләре идарәсе | 2025 ел | | | | 459,64 |

- «2025 ел өчен БАРЛЫГЫ: Җирле бюджет акчалары:» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

| | |
|---|---|
| 2025 ел өчен БАРЛЫГЫ:<br>Җирле бюджет акчалары: | 5505,502 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов